ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЦИПЬИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЧЕПЬЯ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
« 08» декабря 2023 г.

**КАРАР**
№ 204

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 31 мартындагы 4 номерлы «2020 елда Чепья авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Чепья авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 31 мартындагы 4 номерлы «2020 елда Чепья авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» карарына, исемдәге «2020 елда» сүзен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 31 мартындагы 4 номерлы «2020 елда Чепья авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау хакында» карары белән расланган 2020 елда Чепья авыл җирлегенең Салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.1. исемендә «2020 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.2. 3 пунктта «, муниципаль программаларның структур элементлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.3. 7 пунктта «һәм хисап чорына кадәрге елда» сүзләрен «, шулай ук хисап финанс елына кадәрге 6 ел эчендә муниципаль берәмлекнең стимуллаштыручы салым чыгымнары турында мәгълүмат» сүзләренә алмаштырырга;

- икенче абзацта «,муниципаль программаларның структур элементларына» сүзләрен төшереп калдырырга;

- өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«түләүчеләр тарафыннан бирелгән ташламаларга ихтыяҗ булу, ул биш ел эчендә ташламаларга хокуктан файдаланучы түләүчеләр санының һәм

ташламалар кулланугa потенциаль хокукка ия түләүчеләр санының яки түләүчеләрнең гомуми санының нисбәте белән характерлана.»;

2.5. 16 пунктның беренче абзацында «муниципаль берәмлекнең муниципаль программалары салым чыгымнарының 1 сумына» сүзләрен «муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының 1 сумына» сүзләренә алмаштырырга;

2.6. 17 пунктта:

- беренче абзацта «1 октябрьгә кадәр» сүзләрен «ел саен, 1 октябрьгә кадәр,» сүзләренә алмаштырырга;

- өченче абзацта «социаль-икътисадый сәясәт юнәлешләре (максатлары)» сүзләрен «муниципаль программаларга карамаган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатлары» сүзләренә алмаштырырга;

2.7. кушымтага түбәндәге эчтәлекле 19 позиция өстәргә:

"

| | | |
|---|---|---|
| 19. | Салым түләүчеләрнең (берәмлекләрнең) гомуми саны | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе |

»

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Чепья авылы башкарма комитеты җитәкчесе И.Н. Галиев